ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган үрнәк укыту планы буенча татар әдәбияты укыту фәненең мәҗбүри өлешендә база дәрәҗәсендә өйрәнелә. Укыту планы 8 нче сыйныфта татар әдәбиятын укыту ана теле һәм әдәбиятын укытуның **икенче баскычына** (5-9 нчы сыйныфлар) туры килә**.** Бу чорда тормышның төрле өлкәләренә караган, төрле һөнәр ияләренең язмышларын чагылдырган әдәби әсәрләр белән танышуга, аларны тиешенчә аңларга, матурлык ноктасыннан бәяләп кабулитәргә өйрәнүгә игътибар ителә. Халык авых иҗатының төрле төрләренә, аларның үзенчәлекләренә игътибар ителеп, фольклор белән әдәбият арасындагы тыгыз бәйләнеш күрсәтелә. Укучыларның сөйләм телен үстерүгә зур урын бирелә, әдәбият теориясеннән башлангыч мәгълүмат бирелә.

## ПРЕДМЕТНЫ ӨЙРӘНҮНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Урта сыйныфларда әдәбиятны укытуның **төп максаты** булыпматур әдәбият әсәрләрен форма һәм эчтәлек берлегендә аңларга һәм анализларга өйрәтү, логик фикерләү сәләтен үстерү һәм камилләштерү, балаларның рухи дөньяларын баету тора. Бу процесс өч – гамәли, гомуми белем бирү, тәрбияви - яссылыкларны берләштереп алып барылырга тиеш. Әлеге максат түбәндәге **бурычларны** алга куя:

- Укучының төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белүенә ирешү һәм анализ барышында кулланырга күнектерү;
- укучыда матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;
- укучының телдән һәм язма сөйләмен үстерү;
- укучыда үз милләтенә, аның әдәбиятына, мәдәниятенә карата хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, үз милләтенең, шушы төбәктә яшәүче башка халыкларның мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.

1. Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
2. Әдәби әсәрне өлешчә анализлау күнекмәләре булдыру.
3. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрнеятлату.
4. Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.

## УКУ ФӘНЕНЕҢ УКУ ПЛАНЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

5-9 сыйныфларда сәгатьләр бүленеше.

| Сыйныф | Атнага | Барлык сәгать | Барлык уку атнасы |
|---|---|---|---|
| 5 сыйныф | 2 сәгать | 70 сәгать | 35 атна |
| 6 сыйныф | 2 сәгать | 70 сәгать | 35 атна |
| 7 сыйныф | 2 сәгать | 70 сәгать | 35 атна |
| 8 сыйныф | 2 сәгать | 70 сәгать | 35 атна |
| 9 сыйныф | 2 сәгать | 68 сәгать | 34 атна |

## УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Татар әдәбияты буенча уку курсының төп гомуми белем дәрәҗәсендә өйрәнү укучыларда әдәби әсәрне кабул итү, анализлау, бәяләү, эстетик зәвык тәрбияләү, иҗади фикерләүне үстерү нәтиҗәсе булып тора.

**1) Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгели алу;
- үз халкыңның тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләренә ия булу;
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген, милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булу, һөнәр турында җитди караш формалашу;
- әсәрдә гореф-гадәтләр һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булу;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз-үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу, гомумкешелек сыйфатларына ия булу;
- илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисенә төшенү, Ватаныбыз тарихына сакчыл карашлы булу;
- рухи байлыкның зур бәхет булуын аңлау.

**2) Метапредмет нәтиҗәләр:**

Әдәбиятны иҗтимагый һәм мәдәни тормыш-күренешләре белән бәйлелектә аңлау.

**3) Танып-белу гамәлләре:**

- гомум уку гамәлләре (танып белу мәсьәләсен аңлау, төрле жанрдагы текстлардан кирәкле мәгълүматны аерып чыгару, өйрәнелә торган  материал эчендә төп фикерне билгеләү, белемне структуралаштыру, нәтиҗәләр, гомумиләштерүләр ясау);
- логик уку гамәлләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын эшләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү);
- проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәгъбир итү, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйль эшләү).

**4) Коммуникатив гамәлләр:**

- хезмәттәшлек итү;
- тел нормаларына туры китереп, монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;
- үз фикерләрен тәгъбир итү;
- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;
- фикерләрне дәлилләп җиткерү;
- сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү;
- фикерләрне эзлекле рәвештә, мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру;
- Регулятив гамәлләр:
- уку мәсьәләсен кую;
- фаразлау;
- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү;
- узенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контрольдә тотып бәяли алу;
- узанализ һәм үзбәя ясау.

**5) Предмет нәтиҗәләр:**

- халык авыз иҗаты - дастан жанрын үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;
- әдәбият аша образлы фикерли алу.

## ФӘННИ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

**Уку елы ахырына 7 нче сыйныф укучылары белергә тиеш:**

- тәкъдим ителгән эпик, лирик һәм драматик әсәрләрне уку һәм аларга үз мөнәсәбәтең, бәяң булу;
- сайлап алган әсәрнең (кыскача, тулы, аерым бүлекләренең) эчтәлеген сөйли белү;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлын, иҗатын сөйләү;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын исбатлау;
- әдәби әсәрнең темасын, төп фикер – идеясен билгеләү;
- әдәби әсәр героена характеристика бирү;
- эпик әсәрнең бер өлешен образлы сөйләү;
- шигырьне яттан белү яки прозадан өзекне яттан сөйләү;
- бер яки берничә әсәр геройларын чагыштырып, уртак һәм үзенчәлекле якларын табу;
- төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;
- әдәби әсәрнең әһәмиятен, кыйммәтен, үзенчәлекләрен дәлилле итеп аңлата, исбатлый белү;
- автор сөйләмен һәм персонажлар телен анализлау;
- әдәби әсәр буенча сочинение язу;
- бер минутка 70-115 сүз уку.

**7 нче сыйныф укучылары ия булырга тиешле күнекмәләр:**

- эпик әсәр буенча изложение язу;
- әдәби әсәрнең төрләрен аера алу;
- әсәрнең сәнгать күренеше икәнлеген аңлата алу;
- бер яки берничә әсәр геройларын чагыштырып, уртак һәм үзенчәлекле якларын табу;
- төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;
- әдәби әсәрнеңә һәм иятен, кыйммәтен, үзенчәлекләрен дәлилле итеп аңлата, исбатлый белү;
- әсәрдә сюжет элементларына ера, композициясен, тел-сурәтләү чараларын күрсәтә, аңлата белү;
- автор сөйләмен һәм персонажлар телен анализлау;
- әдәби әсәр буенча сочинение язу;
- татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бертөрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау;
- ирекле темага сочинение язу.
- бер минутка 80-125 сүз уку.

Дәреслек белән эшләү, конспектлар төзү, белешмә әдәбияттан (төрле сүзлекләрдән, тәнкыйть материалларыннан, фәнни чыганаклардан һ.б.) файдалану күнекмәләре булу.

## ЭШ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Төрләр һәм жанрлар. Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Әдәби алымнар (кеше образы тудыруга караган алымнар). Әдәби төр, жанр, эчтәлек һәм форма, әдәби алымнар турында белемнәр системага салына, тирәнәйтелә.

**Сәнгать төре буларак әдәбият.**Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып-белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

**Халык авыз иҗаты.** Дастан жанрына хас сыйфатлар, аның төркемчәләре. Тарихи дастан буларак «Идегәй» дастаны (өзекләр**)**.

**XX гасыр башы**нда сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. **Г.Тукай тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре. Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре.

**Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Яшь ана» хикәясе. Әсәрдә хикәя жанры үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. **Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Акчарлаклар» повесте (өзекләр). Әсәрдә жанр үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт образы (хронотоп).

**Чор: 1920-1930 еллар әдәбияты. Әдәби барышка тәэсир иткән тарихи сәбәпләр. Аларның әдәбиятны каршылыклы үсешкә китерүе.** Әдәби әсәрләр төрлелек**:** милли традицияләрне дәвам иттерүче һәм яңа идеология кысаларында иҗат ителгән әсәрләр**.**

**Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** “Мокамай” поэмасы. Лиро-эпик жанр – поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт. Текст: эпиграф, багышлау.

**Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Җан Баевич» комедиясе. Драма төренең комедия жанры турында белгәннәрне тулыландыру. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

**Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү** “Кызыл чәчәкләр” повесте. Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**.**

**Чор әдәбияты.** XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы, аның тарихи сәбәпләре. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр**.**

**С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Лирик жанр – күңел лирикасы. Тел-стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре.

**Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе.

**Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әни килде» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәбиижат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

**Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Тәүге соклану», “Ярсулы яз” хикәяләре. Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья.

**М.Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Без кырык беренче ел балалары» повесте. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

**М.Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү. “Уйна әле” хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**.**

**Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Язмышның туган көне» хикәясе. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары.

**З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Сәер кыз» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль.

**Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр.

**Р. Фәйзуллинның тормыш юлына кыскача күзәтү.** “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь” әсәрләре, лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү.

**Дәрестән тыш уку өчен әсәрләр:**
1. Г.Исхакый “Кәҗүл читек”
2. С.Хәким “Дәверләр капкасы” Укучылар мөстәкыйль рәвештә хәзерге чор әсәрен сайлап укый.
3. Вакытлы матбугатка күзәтү ясау.

**Яттан өйрәнү өчен тәкъдим ителгән әсәрләр исемлеге:**
1. «Идегәй» дастаныннан өзек
2. Г.Тукай “Милли моңнар”.
3. Һ.Такташ “Мокамай” поэмасыннан өзек
4. С.Хәким «Әнкәй»
5. Ш.Хөсәеновның «Әни килде» драмасыннан бер монолог
6. М.Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары» повестеннан өзек

7. Р. Фәйзуллин “Туган тел турында бер шигырь” шигыреннән өзек

**Инша язу өчен үрнәк темалар:**

1. “Минем милләтем – минем горурлыгым”
2.“Чын дустым”
3. “Әнием – бәгырем”
4.“Шинельле һәм шинельсез солдатлар”

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № п/п | Сәгать саны | Төп эчтәлек | Укучыларның эшчәнлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 с. | **Кабатлау. Сәнгать төре буларак әдәбият.** Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, төп билгеләмәләрне язып бару. |
| 2. | 3 с. | **Халык авыз иҗаты. «Идегәй» дастаны.** Дастан жанрына хас сыйфатлар, аның төркемчәләре. «Идегәй» дастанын уку. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. |
| 3. | 3 с. | **Матур әдәбиятның эпик төре. Н.Думави. «Яшь ана» хикәясе.** Әсәрдә хикәя жанры үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; хикәя жанры үзенчәлекләрен әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар күрә, аера белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | 3 с. | **Ш.Камал. «Акчарлаклар» повесте** Әсәрдә жанр үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп). | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу; укыган әсәр эчтәлеге буенча терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; жанр үзенчәлекләрен билгели белү; әдәби әсәрдәге образлылык, образ, символ, деталь, аллегория, табигать образы, әйбер образы, пейзаж, портрет һ.б.күрә, аера белү. |
| 5. | 6 с. | **Повесть жанры. Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.** Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә, аера белү. |
| 6. | 12 с. | **Повесть жанры. М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повесте.** Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). **Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повесте.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә, аера белү. |
| 7. | 6 с. | **Әдәбиятның лирик төре. Г.Тукай. «Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре.** Г. Тукай иҗаты үрнәгендә гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре. **Һ.Такташ. “Мокамай” поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт.Текст: эпиграф, багышлау. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | 7 с. | **С.Хәким. «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре.** Лирик жанр - күңел лирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре. **Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр. **Р. Фәйзуллин. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь” әсәрләре.** Лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. |
| 9. | 5 с. | **Әдәбиятның драматик төре. Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе.** Драма төренең комедия жанры турында белгәннәрне үстерү. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). | Комедия жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу. |
| 10. | 11 с. | **Ш.Хөсәенов. «Әни килде» драмасы.** Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). **З.Хәким. «Сәер кыз» драмасы.** Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль. | Жанрны һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу. |
| 11. | 4 с. | **Татар әдәбиятында бәхет мотивы. Г. Сабитов. «Тәүге соклану», “Ярсылу яз” хикәяләре.** Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. **М.Галиев. “Уйна әле” хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле тереk схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера бел; тема, проблема, идея, пафос, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын дөрес билгеләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | 3 с. | **Г.Гыйльманов. «Язмышның туган көне» хикәясе.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын күрә, аера белү. |
| 13. | 6 с. | **7 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау.** | Күзәтүләргә гомуми нәтиҗә ясый белү. Тулы язма һәм телдән җавап бирә белү. |

## КАЛЕНДАРНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ / КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № п/п | Тема урока/дәрес темасы | Дата проведения/Үткәрү датасы | |
|---|---|---|---|
| | | план | факт |
| | **Повторение./ Кабатлау** | | |
| **1.** | Литература как вид искусство./ Сәнгать төре буларак әдәбият | | |
| | **Устное народное творчество./ Халык авыз иҗаты** | | |
| **2.** | Дастан как один из жанров устного народного творчества. Дастан “Идегей”./ Халык авых иҗатының бер жанры буларак дастан. “Идегәй” дастаны | | |
| **3.** | Дастан “Идегей”. Содержание, проблематика произведения./ “Идегәй” дастаны. Әсәрнең эчтәлеге, проблематикасы | | |
| **4.** | Дастан “Идегей”. Образы Идегея и “Идегәй” дастаны. Идегәй һәм Туктамыш образлары | | |
| | **Литература начала XX века./ XX гасыр башы әдәбияты** | | |
| **5.** | Литература начала XX века./ XX гасыр башы әдәбияты | | |
| **6.** | Жизнь и творчество Г.Тукая. Стихотворения “Нации”, “Национальные мелодии”./ Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Милләтә”, “Милли моңнар” шигырьләре | | |
| **7.** | Стихотворения Г.Тукая “Театр”, “Поэт”./ Г.Тукайның “Театр” , “Шагыйрь” шигырьләре. | | |
| **8.** | **Сочинение. “Моя нация – моя гордость”./ “Минем милләтем – минем горурлыгым”** | | |
| **9.** | Жизнь и творчество Н.Думави. Рассказ “Молодая мама”./ Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты. “Яшь ана” хикәясе | | |
| **10.** | Рассказ “Молодая мама” Н.Думави. Проблематика рассказа./ Н.Думавиның “Яшь ана” хикәясе. Хикәянең проблематикасы | | |
| **11.** | Художественная ценность рассказа “Молодая мама” Н.Думави./ Н.Думавиның “Яшь ана” хикәясенең әдәби кыйммәте | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **12.** | Жизнь и творчество Ш.Камала. Повесть “Чайки”./ Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. “Акчарлаклар” повесте | | |
| **13.** | Изучение повести Ш.Камала «Чайки»./ Ш.Камалның “Акчарлаклар” повестен өйрәнү | | |
| **14.** | Жанр повести Ш.Камала «Чайки», характеристика главных героев./ Ш.Камалның “Акчарлаклар” повесте жанры, төп геройларга характеристика | | |
| **Литература 1920-1930-х годов./ 1920-1930 еллар әдәбияты** | | | |
| **15.** | Литература 1920-1930-х годов./ 1920-1930 еллар әдәбияты | | |
| **16.** | Жизнь и творчество Г.Такташа. Повесть “Мокамай”./ Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты. “Мокамай” повесте | | |
| **17.** | Жизнь и творчество Г.Исхакый. Комедия «Жан Баевич»./ Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты. “Җан Баевич” комедиясе | | |
| **18.** | Изучение произведения Г.Исхакый «Жан Баевич»./ Г.Исхакыйның “Җан Баевич” әсәрен өйрәнү | | |
| **19.** | Жанр комедии Г.Исхакый «Жан Баевич»./ Г.Исхакыйның “Җан Баевич” әсәре. Комедия жанры | | |
| **20.** | Проблема образованности в комедии Г.Исхакый «Жан Баевич»./ Г.Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясендә укымышлылык проблемасы | | |
| **21.** | Сатира и ирония в комедии Г.Исхакый «Жан Баевич»./ Г.Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясендә сатира һәм ирония | | |
| **22.** | Жизнь и творчество Г. Ибрагимова. Повесть “Красные цветы”./ Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Кызыл чәчәкләр” повесте | | |
| **23.** | Содержание повести “Красные цветы” Г.Ибрагимова./ Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестенең эчтәлеге | | |
| **24.** | Проблематика повести “Красные цветы” Г.Ибрагимова./ Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестенең проблематикасы | | |
| **25.** | Обобщение литературы 1920-1930-х годов./ 1920-1930 еллар әдәбиятын йомгаклау | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Литература второй половины XX века./ XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты** | | | |
| **26.** | Жизнь и творчество С.Хакима./ С.Хәкимнең трмыш юлы һәм иҗаты | | |
| **27.** | Образ родной страны в стихотворении С.Хакима “Эти поля, эти долины”./ С. Хәкимнең “Бу кырлар, бу үзәннәр...” шигырендә туган ил образы | | |
| **28.** | Проблематика стихотворения С.Хакима “Мама”./ С.Хәкимнең “Әнкәй” шигыренең проблематикасы | | |
| **29.** | Жизнь и творчество А.Еники. Рассказ «Невысказанное завещание»./ Ә.Еникиның тормыш юлы һәм иҗаты. “Әйтелмәгән васыять” хикәясе | | |
| **30.** | Содержание рассказа А.Еники «Невысказанное завещание»./ Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыять” хикәясенең эчтәлеге. **Тест** | | |
| **31.** | Изучение рассказа А.Еники «Невысказанное завещание»./ Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыять” хикәясен өйрәнү | | |
| **32.** | Национальная проблемака в рассказе А.Еники «Невысказанное завещание»./ Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыять” хикәясендә милли проблематика | | |
| **33.** | Образ Акаби в рассказе А.Еники «Невысказанное завещание»./ Ә.Еникиның “Әйтелмәгән васыять” хикәясендә Акъәби образы | | |
| **34.** | **Сочинение. Нравственные ориентиры в обществе./ Җәмгыятьтә әхлакый ориентирлар** | | |
| **Драматический род литературы и его жанры./ Әдәбиятның драма төре һәм аның жанрлары** | | | |
| **35.** | Жизнь и творчество Ш.Хусаинова. Драма «Белое платье матери»./ Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты. “Әни килде” драмасы | | |
| **36.** | Содержание драмы Ш.Хусаинова «Белое платье матери»./ Ш.Хөсәеновның “Әни килде” драмасынның эчтәлеге | | |
| **37.** | Социально-этическая проблематика в драме Ш.Хусаинова «Белое платье матери»./ Ш.Хөсәеновның “Әни килде” драмасында социаль-этик проблематика | | |
| **38.** | Образ символ, архетип в драме Ш.Хусаинова «Белое платье матери»./ Ш.Хөсәеновның “Әни килде” драмасында образ, символ архетип | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **39.** | Образ матери в драме Ш.Хусаинова «Белое платье матери»./ Ш.Хөсәеновның “Әни килде” драмасы ана образы | | |
| **40.** | **Сочинение. “Мама – душа моя”./ “Әнием - бәгырем”** | | |
| **41.** | Жизнь и творчество Г.Сабитова. Рассказ «Первый восторг». Г.Сабитовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Тәүге соклану” хикәясе | | |
| **42.** | Содержание рассказа Г.Сабитова «Первый восторг»./ Г. Сабитовның “Тәүге соклану” хикәясенең эчтәлеге | | |
| **43.** | Картина деревенской жизни в рассказе Г.Сабитова «Первый восторг»./ Г. Сабитовның “Тәүге соклану” хикәясендә авыл тормышы бирелеше | | |
| **44.** | Символы в рассказе Г.Сабитова «Первый восторг»./ Г. Сабитовның “Тәүге соклану” хикәясендә символлар | | |
| **45.** | Жизнь и творчество М.Магдеева. Повесть «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Без кырык беренче ел балалары” повесте | | |
| **46.** | Изучение повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестен өйрәнү | | |
| **47.** | Содержание повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестенең эчтәлеге | | |
| **48.** | Содержание повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестенең эчтәлеге | | |
| **49.** | Лирические отступления в повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестендә лирик тайпылышлар | | |
| **50.** | Лиризм и орнаментализм в повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестендә лиризм һәм орнаментализм | | |
| **51.** | Мотив судьбы нации в повести М.Магдеева «Мы – дети сорок первого года»./ М.Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повестендә милләт язмышы мотивы | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **52.** | **Сочинение. “Солдаты с шинелью и без шинели”./ “Шинельле һәм шинельсыз солдатлар”** | | |
| **53.** | Жизнь и творчество М.Галиева. Рассказ “Давай сыграй”. М.Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Уйна әле” хикәясе | | |
| **54.** | Жизнь и творчество Г.Гильманова. Рассказ «День рождения судьбы»./ Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗаты. “Язмышның туган көне” хикәясе | | |
| **55.** | Психологизм в рассказе Г.Гильманова «День рождения судьбы»./ Г.Гыйльмановның “Язмышның туган көне” хикәясендә психологизм | | |
| **56.** | Хронотоп в рассказе Г.Гильманова «День рождения судьбы»./ Г.Гыйльмановның “Язмышның туган көне” хикәясендә хронотоп | | |
| **57.** | Жизнь и творчество З.Хакима. Драма “Странная девушка”./ З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Сәер кыз” драмасы | | |
| **58.** | Содержание драмы З.Хакима “Странная девушка”./ З.Хәкимнең “Сәер кыз” драмасының эчтәлеге | | |
| **59.** | Оценка образов в драме З.Хакима “Странная девушка”./ З.Хәкимнең “Сәер кыз” драмасындагы образларга бәяләмә | | |
| **60.** | Проблематика в драме З.Хакима “Странная девушка”./ З. Хәкимнең “Сәер кыз” драмасында прблематика | | |
| **61.** | Жизнь и творчество Р.Хариса. Поэма “Сабантуй”./ Р.Харисның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сабантуй” поэмасы | | |
| **62.** | Содержание поэмы Р.Хариса “Сабантуй”./ Р.Харисның “Сабантуй” поэмасының эчтәлеге | | |
| **63.** | Жизнь и творчество Р.Файзуллина. Стихотворение “Высота”./ Р.Фәйзуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. “Биеклек” шигыре | | |
| **64.** | Стихотворения Р.Файзуллина “Не забывай”, “Стихотворение о родном языке”./ Р.Фәйзуллинның “Онытма син”, “Туган тел турында бер шигырь” шигырьләре | | |
| **Повторение и обобщение изученного./ Өйрәнелгәннәрне гомумиләштерү һәм кабатлау** | | | |
| **65.** | Обзор периодической печати./ Вакытлы матбугатка күзәтү ясау. | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **66.** | Повторение./Кабатлау | | |
| **67.** | Подготовка к котрольному тесту./ Контроль тестка әзерләнү | | |
| **68.** | **Контрольный тест./ Контроль тест** | | |
| **69.** | Анализ контрольного теста./ Контроль тестка анализ | | |
| **70.** | Заключение./ Йомгаклау | | |

## ГРАФИК КОНТРОЛЬНЫХ РАБОТ / КОНТРОЛЬ ЭШЛӘР ГРАФИГЫ

| № п/п | Тема урока/дәрес темасы | Дата проведения/Үткәрү датасы | |
|---|---|---|---|
| | | план | факт |
| 1. | **Сочинение.** “Моя нация – моя гордость”./ “Минем милләтем – минем горурлыгым” | | |
| 2. | **Сочинение.** Нравственные ориентиры в обществе./ Җәмгыятьтә әхлакый ориентирлар | | |
| 3. | **Сочинение.** “Мама – душа моя”./ “Әнием – бәгырем” | | |
| 4. | **Сочинение.** “Солдаты с шинелью и без шинели”./ “Шинельле һәм шинельсыз солдатлар” | | |
| 5. | **Контрольный тест./ Контроль тест** | | |

## НОРМЫ ОЦЕНКИ ЗНАНИЙ / УКУЧЫЛАРНЫҢ УКУЫН ҺӘМ БЕЛЕМ КҮНЕКМӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ

**Сочинениене бәяләү**

7 нче сыйныфта сочинение күләме 130-140 сүз.

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса; җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә; хаталар булмаса яки 1 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик) җибәрелсә, «5» ле куела.

2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, текстның башлам өлешендә төгәлсезлекләр китсә, 3 хата булса, «4» ле куела.

3. Текстның төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлек-лелек сакланмаса, текстның башлам һәм бетем өлешләрендә төгәлсезлекләр китсә, 5 хата (мәсәлән, бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион, ике стиль хаталары) изложениедә, 6 хата сочинениедә җибәрелсә, «3» ле куела.

4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, текстның күләме бик кечкенә булса, 12 хата китсә, «2» ле куела.

**Сөйләм күнекмәләрен бәяләү**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле һәм эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм төзи алса, бирелгән әсәр яки Өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора белсә - "5"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле, әмма эчтәлеге ачылып бетмәгән монологик сөйләм өчен "4"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле итеп сөйли белмәсә, эчтәлекне ачып бетерә алмаса, әңгәмәдә өстәмә сораулар бирелгәндә генә катнашса - "3"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог  төзи алмаса, сорауларга җвап бирә алмаса - "2"ле.

**Анализ күнекмәләрен һәм теоретик белемнәрне бәяләү**

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап, урынлы кулланасыз, анализыгыз нигезле, җавабыгыз теоретик яктан югары оештырылган - "5"ле.

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап тааларны куллану барышында аерым төгәлсезлекләр җибәрәсез, анализ эчтәлек сөйләүгә "борыла" - "4"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында аерым төгәлсезлекләр җибәрәсез, анализ эчтәлек сөйләүгә "борыла" - "4"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр кулланасыз, әмма алар күренешкә туры килми, хаталар ясыйсыз; анализ әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләүдән генә гыйбарәт - "3"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматсыз булуыгыз күренә, аларны җавабыгызда кулланмыйсыз, анализ бөтенләй юк - "2"ле.

## МЕТОДИЧЕСКОЕ ОБЕСПЕЧЕНИЕ / МЕТОДИК КУЛЛАНМА

Программаны ашыру барышында гомуми белем бирү учреждениеләренең 7 сыйныф укучылары өчен «Әдәбият» дәреслеге кулланыла. Дәреслек: Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 1 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Дәүһәрова. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 165. Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 2 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Дәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 190.

**Әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / тез.-ред. А.Әхмәдуллин. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1990
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. - Казан: Мәгариф, 2007.
3. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ тез. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
4. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ тез. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009
5. Дастаннар. - Казан: Мәгариф, 2001.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Заһидуллина Д.Ф Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган басма. - Казан: Мәгариф, 2004.
8. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов А.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.– Казан: Мәгариф, 2006.
9. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.
10. Исламов Ф.Ф. Әдәби викториналар – әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә кыйммәтле чара. - Казан, 2005.
11. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. – Казан: Мәгариф, 2006.
12. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983-2001.
13. Татар әдәбияты. Теория.Тарих./Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйләҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
14. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.


**Күрсәтмә материаллар**

1. Электрон ресурслар: "Бала" китапханәсе, "Татар мультфильмнары", мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә;
2. Аудио һәм видео әсбаплар:
3. Интерактив мультимедиа уку-укыту әсбабы.

## МАТЕРИАЛ ДЛЯ ПРОМЕЖУТОЧНОЙ АТТЕСТАЦИИ / АРАДАШ АТТЕСТАЦИЯ ӨЧЕН МАТЕРИАЛ

Эшнең характеристикасы, төзелеше һәм эчтәлеге.

Эшнең **максаты:** укучыларның 7 сыйныфта татар здзбияты фәне буенча алган белем һәм күнекмәләрен тикшерү, белемнәрен бәяләү.

Тест формасындагы контроль эш үрнәге.

**1. Нәрсә ул дастан?**

а) әдәбиятның бер жанры
ә) рәсем сәнгатенең бер төре
б) әкият
в) хикәя

**2. "Идегәй" дастанында нинди хан идарә итә.**

а) Үтәмеш хан
б) Сәхибгәрәй хан
в) Туктамыш хан
г) дөрес җавап юк.

**3. Матур яңгырашлы,аһәңле,затлы сүз.Ул- данлау, кемнәрнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны, язмышларны еракларга яңгырату,киләчәк буыннар хәтеренә,халык күңеленә язып кую,тарихта калу дигән сүз Бу халык авыз иҗатының нинди төре?**

а)әкият
б)мәкаль
в)дастан

**4. Габдулла Тукай кайчан туган?**

а) 1886ел 26 апрель
б)1903 ел 28 ноябрь
в)1928 ел 13 гыйнвар
г) 1941 ел 1 май

**5. Габдулла Тукайның әтисенең исеме ничек?**

а) Низам
б) Мөхәммәтгариф
в) Заһидулла
г) Гыйрфан

**6. Ничәнче елларда татарларда вакытлы матбугаат барлыкка килә?**

а) 1905-1907;
б) 1900 елларда;
в) 1915-1917 елларда;
г) 1950 елларда.

**7. ”Акчарлаклар”повестеның авторы кем?**

а)Шәриф Камал
б)Миргазиян Юныс
в)Гомәр Бәширов

8. **Н.Думави кайда туган?**

а) Сарман районы Дусай авылында
б) Аксубай районы Яңа Дума авылында
в) Аксубай районы Кармәт авылында

9. **Кайсы Н.Думави шигыре?**

а)”Кар ява”
б)”Ак чәчәкләр ява”
в)”Беренче кар”

10. **Н.Думави кайсы мәдрәсәдә укыткан?**

а)Галия

б)Кизләү
в) Буби

11. **Һ. Такташ ничәнче елда туа?**
а)1901
б)1902
в)1903

12. **Үсә төшкәч Һ.Такташны кайсы авыл мәдрәсәсенә укырга бирәләр?**
а)Кушлавыч
б)Пешлә
в)Кармәт

13. **Һ.Такташ 1921 нче елда кая китә?**
а)Петербургка
б)Ташкентка
в)Самарага

14. **Һ.Такташның дустына багышлап язган шигыре кайсы?**
а)”Мәхәббәт тәүбәсе”
б)”Алсу”
в)”Мокамай”

**15. “Мокамай” әсәрендәге геройның чын исеме.**

А) Мөхәммәтҗан;
Б) Мөхәммәтзакир;
В) Мөхәммәтгазиз.

16. **Х.Туфан музее кайда урнашкан?**
а)Казанда
б)Әтнәдә
в)Иске Кармәттә

17. **Нәрсә ул поэма?**
а) әдәбиятның бер жанры
ә) рәсем сәнгатенең бер төре
б) әкият
в) хикәя

18. **“Җан Баевич” әсәренең жанры?**
А) комедия;
Б) драма;
В) трагедия.

**19. Хикәя әдәбиятның кайсы төренә карый?**
А) лирик
Ә) эпик
Б) драматик

**20. Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә төп тема:**
а )сугыш һәм тынычлык;
б) буыннар арасында бәйләнеш өзелү;
в ) көнчелек.

**21. Г.Ибраһимов яшәгән еллар:**
а) 1887-1938
б) 1900-1938
в) 1838-1887

**22. Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр ”әсәре нинди сүзләрдән башлана?**
а) “Яшәгән булган ди 3 егет”
б) “Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек”
в) “Йомшак гына җил исә...”

**29. Әсәрләрне һәм авторларын туры китереп яз.**
а) Х.Туфан – 1) “Мокамай”

б) Һ.Такташ – 2) “Изге әманәт”
в) Г.Исхакый – 3) “Кайсыгызның кулы җылы”
г) Т.Гыйззәт – 4) “Җан Баевич”

**Укучының эшен бәйләү критерийлары.**

Һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә. Барысы 36 балл

0-16 балл – “2”ле билгесе
17-21 балл –“3”ле билгесе
22-29 балл – “4”ле билгесе
30-36 балл – “5”ле билгесе

**30. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларын атагыз**
(3 мисал).

## ЛИСТ КОРРЕКТИРОВКИ / ТӨЗӘТМӘЛӘР КЕРТҮ БИТЕ

| Название раздела темы/ Бүлек теманың исеме | Причины корректировки/ Төзәтмәләр кертү сәбәбе | Корректирующие мероприятия/ Төзәтмә кертү чаралары | Дата проведения / Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |